КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 3 август г.Казань № 636

Татарстан Республикасында матди булмаган мәдәни мирас объектлары реестры турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Татарстан Республикасында матди булмаган мәдәни мирас турында» 2017 елның 26 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасында матди булмаган мәдәни мирас объектлары реестры турындагы нигезләмәне расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 3 август, 636 нчы
карары белән расланды

# Татарстан Республикасында матди булмаган мәдәни мирас объектлары реестры турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасында матди булмаган мәдәни мирас объектлары реестрын (алга таба – Реестр) булдыру һәм эшләү максатларын, исәпкә алу объектлары составын, мәгълүмат фонды эчтәлеген, Реестрны формалаштыру һәм алып бару тәртибен билгели.

1.2. Реестр әлеге объектларны дәүләт исәбенә алу максатларында бердәйлеге һәм чагыштырырлык булуы Реестрны формалаштыруның гомуми принциплары, алып бару ысуллары һәм формалары исәбенә тәэмин ителә торган матди булмаган мәдәни мирас объектлары турында мәгълүматларны үз эченә алган мәгълүмат системасын тәшкил итә.

1.3. Реестр түбәндәге максатларда төзелә:

матди булмаган мәдәни мирас күзлегеннән кыйммәтле булган объектларны дәүләт исәбенә алу, аларны саклау, өйрәнү һәм популярлаштыру;

Татарстан Республикасында булган теркәлгән матди булмаган мәдәни мирас объектларын игълан итү;

матди булмаган мәдәни мирас объектларын бозып күрсәтүләрдән, тупас аңлатулардан, тарихи контекстан чыгару белән бәйле ялгышулардан саклау;

Татарстан Республикасында булган теркәлгән матди булмаган мәдәни мирас объектлары турында мәгълүмат һәркем файдалан алырлык булу;

Реестрга кертелгән матди булмаган мәдәни мирас объектларын саклауда һәм алга таба өйрәнүдә дәүләт ярдәмен күрсәтү;

язмада булган традицион мәдәният объектларын эзләү, сайлау, системалаштыру мөмкинлекләрен оптимальләштерү;

белгечләрне (этнографлар, филологлар, этномузыкологлар, этноорганологлар, этнохореографлар) һөнәри әзерләү сыйфатын күтәрү һәм мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең, профессионал һәм үзешчән иҗат коллективлары башкаручылары һәм ялгыз башкаручыларның квалификациясен күтәрү.

## II. Реестрның эчтәлеге һәм структурасы

2.1. Реестр Татарстан Республикасының матди булмаган мәдәни мирас объектларын җыю, теркәү, системага салу һәм саклау белән шөгыльләнүче оешмаларында булган матди булмаган мәдәни мирас объектлары турында

мәгълүматтан, матди булмаган мәдәни мирасны саклау һәм популярлаштыру белән кызыксынучы затларда булган материаллардан формалаша.

2.2. Реестрда матди булмаган мәдәни мирас объектлары түбәндәге төрләр буенча төркемләнә:

халык гыйлеме, ышанулары, гадәтләре, традицияләре, фольклор әсәрләре, билгеле бер территориядә даими яңгырый торган йолалар һәм бәйрәмнәр;

башкарма сәнгатьнең, шул исәптән сүз, вокал, уен кораллары һәм бию сәнгатенең уникаль формалары;

халык бизәнү-кулланма сәнгате әйберләре, музыка кораллары, көнкүреш әйберләре эшләү технологияләре;

аерым бер территориядә булган, тарихи формалашкан сюжетларда, образларда һәм аларны гәүдәләндерү стилистикасында тормышка ашырыла торган халык сәнгате кануннары;

матди булмаган мәдәни мирас объектларының әлеге Нигезләмәнең 3.4 пунктында билгеләнгән критерийләргә җавап бирә торган башка төрләре.

## III. Реестрны формалаштыру тәртибе

3.1. Реестрны формалаштыру һәм алып баруга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы булып Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тора (алга таба – Министрлык).

3.2. Реестрны формалаштыру һәм алып бару тәртибе Министрлык боерыгы белән раслана, анда түбәндәгеләр билгеләнә:

Реестрны формалаштыру һәм алып бару вазыйфаларын гамәлгә ашыручы Министрлык ведомствосындагы дәүләт учреждениесе;

Реестрга кертелгән Татарстан Республикасының матди булмаган мәдәни мирас объекты паспорты формасы;

кәгазьдә һәм электрон рәвештә Реестр формасы;

матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектны Реестрга кертү, Ресстрга үзгәрешләр кертү, матди булмаган мәдәни мирас объектын Реестрдан чыгару буенча процедуралар үткәрү этаплары, вакыты һәм эзлеклелеге.

3.3. Матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектны Реестрга кертү турында гариза (алга таба – гариза) матди булмаган мәдәни мирасны саклау һәм популярлаштыру белән кызыксынучы зат тарафыннан бирелергә мөмкин.

3.4. Матди булмаган мәдәни мирас объектларын Ресстрга кертү өчен сайлап алу критерийлары түбәндәгеләр:

тарихи һәм мәдәни әһәмияте;

мәдәни традициядә яки этник, социаль яки конфессиональ төркемнең мәдәни тарихында тамырлану дәрәҗәсе;

мәдәни традицияне уникаль таныклау сыйфатында кыйммәте;

юкка чыгу куркынычы.

3.5. Матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектны Реестрга кертү яисә кертүдән баш тарту өчен нигез булып аның әлеге Нигезләмәнең

3.4 пунктында күрсәтелгән критерийләргә туры килүе яисә туры килмәве турында дәүләт экспертиэзасы бәяләмәсе тора.

3.6. Матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектны Реестрга кертү яисә кертүдән баш тарту турында карар гаризаны Министрлыкта теркәгән көннән соң бер елдан артмаган вакыт эчендә Министрлык боерыгы формасында кабул ителә.

3.7. Министрлык Матди булмаган мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектны Реестрга кертүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә тиешле хәбәрнамәне гариза биргән затка җибәрә.

3.8. Реестрга үзгәрешләр кертү һәм матди булмаган мәдәни мирас объектын Реестрдан чыгару Министрлык билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3.9. Матди булмаган мәдәни мирас объектын Реестрдан чыгару турында карар матди булмаган мәдәни мирас объектын Реестрдан чыгаруның сәбәпләрен нигезләү белән дәүләт экспертизасы бәяләмәсен алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә Министрлык боерыгы формасында кабул ителә.

3.10. Матди булмаган мәдәни мирас объектлары турында мәгълүматларны Реестрга кертү әлеге Нигезләмәнең 3.6 һәм 3.9 пунктлары нигезендә карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 15 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

3.11. Министрлык Реестрга кертелгән матди булмаган мәдәни мирас объектлары турында мәгълүматларның дөреслеген, саклануын һәм актуальлеген тәэмин итә.

3.12. Реестрдагы мәгълүматлар ачык, һәркем файдалана алырлык була һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәг рәсми сайтына (http://mincult.tatarstan.ru) урнаштырыларга тиеш.

---